Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Биектау авыл җирлеге Советы

КАРАР №4

Биектау авылы 2025 елның 14 феврале

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Советының 2023 елның 07 сентябре “Җир салымы турынла” гы 18 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2024 елның 12 июлендәге 176-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Биектауавыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Советының 2023 елның 07 сентябре “Җир салымы турынла” гы 18 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 2 пунктның 4 абзацындагы «(эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән гайре)» сүзләрен «,әлеге абзацта күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган җир кишәрлекләреннән һәм һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган җир кишәрлекләреннән гайре;» сүзләренә алыштырырга;

1.2) 2 пунктның 5 абзацына «, әлеге абзацта күрсәтелгән һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән җир кишәрлекләреннән гайре;» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карар үз көчен 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә җәелдерә.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең түбәндәге адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Татарстан Республикасы Балык Бистәсе районы, Биектау авылы, Х. Сафиуллин ур., 4 йорт; Балык Бистәсе районы, Околоток-Яңасала авылы, Калинин ур., 102 йорт, Балык Бистәсе районы, Чаллы-Баш авылы, ур. М. Горький урамындагы 69 нчы йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Биектау авыл җирлеге башлыгы Р.К.Сахапов